ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 10 » март 2021ел.** **№ 153**

**Җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүдә гражданнарга бердәм электрон социаль юл йөрү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча хезмәт күрсәтүләр белән бәйле алынмаган керемнәрне каплау максаты белән оешмаларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү Тәртибен раслау турында**

Арча муниципаль районы прокуроры протесты, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына аерым категория гражданнар өчен Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында айлык бердәм социаль юл йөрү билетын һәм айлык бердәм балалар социаль юл йөрү билетын бирү Тәртибен раслау турында» 2005 елның 7 апрелендәге 161 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр формасында грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының һәм Россия Федерациясе

кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында" 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары белән билгеләнгән таләпләргә таянып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүдә гражданнарга бердәм электрон социаль юл йөрү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча хезмәт күрсәтүләр белән бәйле алынмаган керемнәрне каплау максаты белән оешмаларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү Тәртибен әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә аерым категория гражданнар өчен транспорттан бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган итеп Арча муниципаль районы башкарма комитетын билгеләргә.

3. Әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә субсидия алу хокукына дәгъва кылучы юридик затларны, шәхси эшкуарларны, физик затларны сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссия составын расларга.

4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 20 мартындагы 192 номерлы "Җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүдә гражданнарга бердәм электрон социаль юл йөрү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча хезмәт күрсәтүләр белән бәйле алынмаган керемнәрне каплау максаты белән оешмаларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында" карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (arsk.tatarstan.ru).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И.Ә. Галимуллинга йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Мөхәрәмов

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
10.03.2021 ел, № 153 карарына
1 нче кушымта

Җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүдә гражданнарга бердәм электрон социаль юл йөрү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча хезмәт күрсәтүләр белән бәйле алынмаган керемнәрне каплау максаты белән оешмаларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү
Тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78 статьясы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә аерым категория гражданнар өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде һәм Арча муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга җәмәгать транспорты хезмәтләреннән аерым категория гражданнарны бердәм электрон социаль юл билетлары буенча (ташламалы транспорт картасы) йөртүдән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле рәвештә алынмаган керемнәрне каплау өчен Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен билгели.

1.2. Татарстан Республикасында аерым категория гражданнар өчен транспорт хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында айлык бердәм социаль юл йөрү билетын һәм айлык бердәм балалар социаль юл йөрү билетын бирү Тәртибен раслау турында» 2005 елның 07 апрелендәге 161 номерлы карары (алга таба - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 07 апрелендәге 161 номерлы карары) нигезендә кертелгән бердәм социаль юл йөрү билетларын һәм айлык бердәм балалар социаль юл йөрү билетларын сату юлы белән тәэмин ителә.

1.3. Субсидияләр Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә гомуми файдаланудагы муниципаль һәм муниципальара маршрутларда пассажирлар йөртү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы транспорт оешмаларына бердәм электрон социаль юл йөрү билетлары буенча гражданнарның аерым категорияләренә җәмәгать транспорты хезмәтләрен күрсәтүгә бәйле рәвештә тотылган чыгымнарны компенсацияләү максатыннан бирелә.

1.4. Субсидия бирү өчен юридик затларны, шәхси эшмәкәрләрне, физик затларны сайлап алу критерийлары булып коры җир пассажир транспорты эшчәнлеге: шәһәр эчендә һәм шәһәр янында пассажирлар йөртү тора.

1.5. Субсидия вәкаләтле органга - Арча муниципаль районы башкарма комитетына Арча район Советының тиешле финанс елына һәм план чорына бюджет турында карарында билгеләнгән бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм әлеге Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән максатларда каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

1.6. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетында тиешле финанс елына каралган субсидияләр Арча муниципаль районы Башкарма комитетының Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы Казначылык департаментының Арча муниципаль районы Территориаль бүлегендә ачылган счетында исәпкә алына.

1.7. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә аерым категория гражданнар өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган түбәндәгеләрне башкара:

- әлеге Тәртипнең 3.1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә гражданнарның аерым категорияләренә бердәм айлык социаль юл йөрү билеты һәм бердәм айлык балалар социаль юл йөрү билеты (ташламалы транспорт кушымтасы булган электрон карталар) буенча хезмәт күрсәтүләр белән бәйле чыгымнарны компенсацияләү максатыннан транспорт оешмаларына түләнергә тиешле субсидияләрне исәпли (исәп-хисап белешмәсен әзерли);

- Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру һәм финанс чараларын тоту турында хисап бирә.

1.8. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ Арча муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге биргән белешмәләр буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында бюджет турындагы карар нигезендә, яисә бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү турында карар, катнашучыны сайлап алуны үткәрү турында мәгълүмат (субсидия

сайлап алу нәтиҗәләре буенча бирелгән очракта) нигезендә бирелергә тиешле субсидияләр турында мәгълүмат урнаштыра.

## II. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Субсидия алуга дәгъва кылучылар яисә гариза (заявка) һәм субсидия алуга документлар тапшыруга вәкаләтле башка затлар (алга таба - мөрәҗәгать итүчеләр) вәкаләтле органга түбәндәге документларны тапшыралар:

1) әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә билгеләнгән рәвештәге субсидия бирүгә заявка;

2)күләмен нигезли торган мәгълүматны күрсәтеп, субсидиянең күләмен исәпләү (исәпләү формулалары һәм аларны куллану тәртибе, чыгымнар нормативлары, статистик күрсәткечләр һәм субсидия бирү максатларыннан чыгып, башка мәгълүмат);

3) мөрәҗәгать итүче раслаган җитәкченең вәкаләтләрен раслый торган документ күчермәсе яисә вәкаләтле затка карата расланган ышаныч кәгазе;

4) әлеге Тәртипнең 1.4 пунктында билгеләнгән критерийларны раслый торган документлар;

5) субсидия бирү максатларында автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча персональ мәгълүматларны эшкәртүгә: җыю, язу, системалаштыру, саклау, тапшыру (тарату, зарарсызлау, блок кую, бетерү, юк итү), аерым алганда, «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктында каралган гамәлләр кылуга ризалык;

2.1.1. Субсидия алучылар килешү төзү планлаштырылган айдан алдагы айның беренче числосына түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

субсидия алучыларның салымнар, җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, түләнергә тиешле процентлар (мондый таләп хокукый акт белән каралган очракта) түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш;

субсидия алучыларның хокукый акт нигезендә субсидияләр бирү планлаштырыла торган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына кире кайтару буенча кичектерелгән бурычы, аның бюджетыннан хокукый акт нигезендә (физик затларга субсидия алучылар тарафыннан товарлар китерүгә (эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә) бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү яки каплау максатларында муниципаль учреждениеләргә бирелә торган субсидияләрдән тыш) субсидияләр бирү планлаштырыла торган гавами-хокукый берәмлек алдында акчалата

йөкләмәләр буенча кичектерелгән (җайга салынмаган) бурыч (шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә) һәм башка хокукый актлар нигезендә бирелгән субсидияләр, бюджет инвестицияләре булмаска тиеш;

субсидия алучылар үзгәртеп кору, бетерү процессында булмаска, аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән булырга тиеш, субсидия алучыларның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, шәхси эшкуарлар эшчәнлекне шәхси эшкуар сыйфатында туктатырга тиеш түгел;

катнашучы булган субсидия алучыларның дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчеләр, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, башкарма орган функциясен үтәүче билгеле бер зат яисә баш бухгалтер турында, шәхси эшкуар һәм товарлар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик зат турында белешмәләр булмау;

чит ил юридик затлары, шулай ук салым салуның ташламалы салым режимын бирә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналары) үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләрнең Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлегенә кергән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган чит ил юридик затларының катнашу өлеше устав (җыелма) капиталында барлыгы 50 проценттан артып киткән Россия юридик затлары булмаска тиеш;

субсидия алучылар субсидия бирү планлаштырыла торган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетыннан акчаларны хокукый акт белән билгеләнгән максатларга башка норматив хокукый актлар нигезендә алмаска тиеш.

2.2. Субсидия алучының нәтиҗәлелеге күрсәткече булып гражданнарның аерым категорияләренә җәмәгать транспорты хезмәтләрен күрсәтүгә бәйле рәвештә тотылган чыгымнарын компенсацияләү тора.

2.3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге кергән гаризаларны кабул итә һәм терки.

Гаризаны теркәгән көннән алып 2 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты субсидия алу хокукына дәгъва кылучы оешмаларны сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссиягә (алга таба - Комиссия) чакыра, ул кергән документларны карый һәм килешү төзү турында яисә юридик зат, шәхси эшмәкәр, физик зат әлеге Тәртипнең 2.1.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә

туры килмәгән очракта, килешү төзүдән баш тарту турында беркетмә рәвешендә карар кабул итә.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге Комиссия карар кабул иткәннән соң 1 эш көне эчендә субсидия алучыга кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Субсидия бирү турында карар кабул ителгәндә, беркетмә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының исәп һәм хисаплылык бүлегенә җибәрелә.

2.4. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

- субсидия алучы тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә күрсәтелгән документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

- субсидия алучының әлеге Тәртипнең 2.1.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

- субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы.

2.5 Субсидия алучыга субсидия бирү өчен нигез булып Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты белән субсидия алучы арасында әлеге Тәртипкә кушымта нигезендәге форма буенча төзелгән субсидия бирү турында Килешү тора.

Субсидия бирү турындагы Килешүдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

- Якларның хокуклары һәм бурычлары, акчаларны күчерү, хисап бирү шартлары һәм тәртибе, килешүнең гамәлдә булу вакыты, аның үтәлешен тикшереп тору, бүлеп бирелгән субсидиянең нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү, килешүне өзү тәртибе, килешүгә өстәмә килешү төзү тәртибе, агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калган өлешен кире кайтару тәртибе.

- субсидияләр бирү буенча Татарстан Республикасы «Арча муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү чыганагы максатчан билгеләнештәге бюджетара трансфертлар булса, җирле бюджеттан субсидияләр бирү турында килешүләр төзү таләбе;

- бюджет чараларын алучы буларак баш бүлүчегә Килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган элек җиткерелгән бюджет чаралары

лимитларын киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү яисә яңа шартлар буенча килешүгә ирешмәгәндә, Килешүне өзү шартларын килешүгә кертү таләбе.

2.7. Субсидияләр Арча муниципаль районы башкарма комитетының исәп һәм хисаплылык бүлеге тарафыннан әлеге Тәртипнең 2.1. һәм 2.1.1. пунктларында күрсәтелгән документларны карау нәтиҗәләре буенча Комиссия карар кабул иткәннән соң унынчы көннән дә соңга калмыйча, әлеге Тәртип белән билгеләнгән срокларда Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында әлеге максатларга каралган акчалар чикләрендә субсидияләрне алучылар тарафыннан ачылган исәп-хисап яисә корреспондентлык счетларына күчерелә.

2.8. Субсидия бирү турындагы килешүнең мәҗбүри шарты - Арча муниципаль районы башкарма комитеты, Арча муниципаль районы контроль-хисап палатасы һәм «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ тарафыннан аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүләрне финанс контролендә тотуга субсидия алучының ризалыгы.

2.9. Арча муниципаль районы башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Контроль-хисап палатасы һәм "Арча муниципаль районының финанс-бюджет палатасы" МКУ субсидия алучыларга субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен мәҗбүри тикшерәләр.

2.10. Хисап бирүгә таләпләр түбәндәгеләрне күздә тота: субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 1.3; 1.4; 2.2. пунктларында күрсәтелгән нәтиҗәләргә, күрсәткечләргә ирешү турында хисап бирү тәртибен, шулай ук срокларын һәм формасын билгеләү (мондый күрсәткечләр билгеләнгәндә) һәм бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүченең Килешүдә субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисап бирү срокларын һәм рәвешләрен билгеләү хокукын күздә тота.

2.11. Әлеге документның 1.5 пунктында күрсәтелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары җитмәүгә бәйле рәвештә аңа агымдагы финанс елында субсидия бирү мөмкин булмаган очракта, әлеге документның 1.4 пунктында күрсәтелгән сайлап алу категорияләренә һәм (яисә) критерийларына туры килгән субсидия алучыга чираттагы финанс елында субсидия бирү субсидия алучының күрсәтелгән категорияләргә һәм (яисә) сайлап алу критерийларына туры килүен кабат тикшермичә гамәлгә ашырыла.

## III. Автотранспорт предприятиеләренең гражданнарга ташламалы транспорт карталары буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле чыгымнарын компенсацияләү күләмен исәпләү методикасы

3.1. Арча муниципаль районы транспорт оешмасының гражданнарга ташламалы транспорт карталары буенча транспорт хезмәтләре күрсәтү сәбәпле чыгымнарын Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсацияләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

Ктр.орг. = (SUM (Тiгор x П1) + SUM (Тiпр x Рiпр) - Втр.орг.,

биредә:

Ктр.орг - транспорт оешмасына ташламалы транспорт карталары буенча гражданнарга транспорт хезмәте күрсәтелүгә бәйле рәвештә Арча муниципаль районындагы транспорт оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан компенсация күләме;

i - транспорт оешмасында транспорт төрләре (автобус);

Тiгор - шәһәрдә пассажирлар йөртүнең Арча муниципаль районы законнары нигезендә i -транспорт төре буенча билгеләнгән гамәлдәге тарифы;

Тiпр - Арча муниципаль районы законнары нигезендә i -транспорт төренә карап билгеләнгән шәһәр яны юлларында пассажирлар йөртү тарифы.

Ташламалы транспорт кушымталы электрон карта белән түләгәндә тарифлар Татарстан Республикасы Дәүләт комитетының тарифлар буенча карары белән билгеләнгән транспортның i-нче төре буенча 50 һәм аннан артык йөрүгә озак вакытлы файдаланудагы билетлар белән йөрү өчен түләү тарифлары кулланыла;

Рiпр - шәһәр янында хисап аена түләүнең автоматлаштырылган системасы операторлары мәгълүматлары буенча башкарылган пассажир-километрлар саны;

Пi - транспорт оешмасы буенча хисап аена i-нче транспорт төрендә юл йөрү билетлары һәм балаларюл йөрү билетлары буенча башкарылган сәфәрләр саны:

сәфәрне шәхсән исәпкә алу булганда - хисап аена АСОП операторлары мәгълүматлары буенча транзакцияләрнең факттагы саны;

сәфәрләрне шәхсән исәпкә алу булмаганда, Пi күрсәткече түбәндәге формула буенча билгеләнә:

Пi = (РВ + РД)х 50 йөрү хДi,

биредә:

РВ - хисап аена Арча муниципаль районында сатылган юл йөрү билетлары саны;

РД - Арча муниципаль районында хисап аенда сатылган балалар юл йөрү билетлары саны;

Дi-Арча муниципаль районында хисап чорына үтәлгән транспорт хезмәтләре күләмендә транспорт оешмасы өлеше, ул Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тәкъдиме нигезендә Арча муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә;

Втр орг. - транспорт оешмасының хисап аена юл йөрү билетларын һәм балалар юл йөрү билетларын сатудан кереме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

Втр орг. = (ЦВ x РВ + ЦД x РД) x Дтр.орг.,

ЦВ - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән юл билеты бәясе;

РВ - хисап аена Арча муниципаль районында сатылган юл билетлары саны;

ЦД - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән балалар юл йөрү билеты бәясе;

РД - Арча муниципаль районында хисап аенда сатылган балалар йөрү билетлары саны;

Дтр.орг - транспорт оешмасының Арча муниципаль районы буенча башкарылган транспорт хезмәтләре күләмендәге өлеше.

## IV. Субсидияләрне кире кайтару тәртибе

4.1. Субсидия алучы аны бирү шартларын бозган очракта, субсидияне күчерү хокук бозуларны бетергәнче туктатыла.

4.2. Субсидияләр бирүнең шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру һәм аларны бозган өчен җаваплылык:

а) Арча муниципаль районы башкарма комитеты, Арча муниципаль районының контроль-хисап палатасы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ тарафыннан субсидия алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүгә мәҗбүри тикшерү үткәрә;

б) субсидияләр бирүнең шартлары, максатлары һәм тәртибе бозылган очракта, түбәндәге җаваплылык чаралары кулланыла:

- субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән бюджет акчаларын алучы буларак һәм Арча муниципаль районының контроль-хисап палатасы тарафыннан уздырылган тикшерүләр фактлары буенча, шулай ук әлеге Тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләр киму очрагында, таләп алынган көннән алып 60 көн эчендә субсидия акчаларын Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетына кире кайтару.

4.1. Субсидия алучы әлеге акчаларны Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетына кире кайтарудан баш тарткан очракта, аларны түләтү суд тәртибендә гамәлгә ашырыла.

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
"10" март 2021ел, №153
карарына 1 нче кушымта

Субсидия алу хокукына дәгъва кылучы юридик затларны, шәхси эшкуарларны, физик затларны сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссиягә ______________________________
(оешма атамасы)

адресы: ___________________________
« __ »________________20__ел

**Субсидия бирүгә (күчерүгә)**

**ЗАЯВКА**

Гражданнарга бердәм айлык социаль юл йөрү билеты һәм бердәм айлык балалар социаль юл йөрү билеты буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле автотранспорт предприятиесе чыгымнарын компенсацияләүгә __________суммада (цифрлар һәм сүзләр белән) субсидия бирүне (күчерүне) тәэмин итүегезне сорыйм.

Субсидия күләме исәбе:_________________________

Теркәлгән документлар:

1. Гражданнарга бердәм айлык социаль юл йөрү билеты һәм бердәм айлык балалар социаль юл йөрү билеты буенча транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле автотранспорт предприятиесе чыгымнарын раслаучы документлар.

Җитәкче (физик зат) _____________________________________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Баш хисапчы (учреждениеләр өчен) __________________________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

МУ

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
"10" март 2021ел, №153
карарына 2 нче кушымта

.

Субсидия алу хокукына дәгъва кылучы юридик затларны, шәхси эшкуарларны, физик затларны сайлап алуны гамәлгә ашыручы комиссия
СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Галимуллин И.Ә.- | Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Галимова С.П. - | «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ җитәкчесе (килешү буенча) |
| Галимуллина Г.Х.- | Арча муниципаль районы башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге башлыгы; |
| Ибраһимов А.Ф.- | Арча муниципаль районы башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы; |
| Гәрәев М. Р.- | Шәһәр төзелеше һәм архитектура секторы мөдире |

Җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүдә гражданнарга бердәм электрон социаль юл йөрү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча хезмәт күрсәтүләр белән бәйле алынмаган керемнәрне каплау максаты белән оешмаларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү Тәртибенә
1 нче кушымта

**Субсидия бирү турында**

**килешү**

**№____** «____» __________202__ ел

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты исеменнән ____________ нигезендә эш итүче, алга таба «Башкарма комитет» дип аталучы _________________ йөзендә бер яктан һәм алга таба ________________ нигезендә эш итүче “Субсидия алучы” дип аталучы ______________йөзендә икенче яктан түбәндәгеләр турында әлеге килешүне төзеделәр.

## 1. Килешү предметы

1.1. Килешү предметы булып җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүдә гражданнарга бердәм электрон социаль юл йөрү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча хезмәт күрсәтүләр белән бәйле алынмаган керемнәрне каплау максаты белән оешмаларга Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы бюджетыннан бушлай һәм кире кайтарылмый торган субсидияләр бирү тора.

## 2. Якларның хокуклары һәм бурычлары

2.1. Башкарма комитетның бурычлары:

2.1.1. Субсидия алучыга бюджет финанславы кысаларында җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле гражданнарның аерым категорияләрен 20___ елның 1 гыйнварыннан 20__ елның 31 декабренә кадәрге чорда электрон бердәм социаль юл йөрү билетлары буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатыннан, Арча муниципаль районы бюджетыннан оешмаларга субсидияләр

бирү тәртибе нигезендә гражданнарга транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле чыгымнарны бюджет финанславы кысаларында алынмаган керемнәр күләмендә каплау;

2.2. Субсидия алучының бурычлары:

2.2.1. Ташламалы транспорт карталары буенча гражданнарга транспорт хезмәтләре күрсәтү.

2.2.2. Әлеге Килешүгә 2 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча башкарма комитетка хисап аеннан соң килгән айның 6 числосыннан да соңга калмыйча, шулай ук әлеге Килешүгә 1 нче кушымтада билгеләнгән форма буенча электрон бердәм социаль юл йөрү билетлары буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә компенсация түләүләрен исәпләү буенча хисап тапшыру.

2.2.3. Агымдагы елның декабрь ае өчен хисаплар Субсидия алучы тарафыннан киләсе елның беренче 10 эш көне дәвамында тапшырыла.

2.3. Башкарма комитет Субсидия алучының әлеге Килешү буенча билгеләнгән бурычларын үтәвен тикшереп торырга, шулай ук әлеге тикшерүне гамәлгә ашыру өчен субсидия алучыдан кирәкле һәм җитәрлек мәгълүмат соратып алырга хокуклы.

2.4. Субсидия алучы Башкарма комитеттан тиешле сорату алынган көннән алып 5 (биш) эш көне эчендә Башкарма комитетка өстәмә мәгълүмат бирергә тиеш.

## 3. Исәп-хисап шартлары һәм тәртибе

3.1. Субсидияләр Субсидия алучыга Арча муниципаль районы бюджетында әлеге Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән максатларга акчалар булганда, субсидия бирү турындагы килешүне имзалаган көнгә кадәр барлыкка килгән алынмаган керемнәргә карата субсидия бирү турында килешү төзелгән көннән алып 5 (биш) эш көне эчендә күчерелә. Алга таба субсидия Субсидия алучыга ай саен Арча муниципаль районы бюджетында әлеге Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән максатларга акчалар булганда, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге Тәртипнең 2.1 пунктларында каралган документларны биргән көннән алып 5 (биш) эш көне эчендә күчерелә. Әлеге Килешүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән максатларга акчалар булмаган очракта, субсидия Арча муниципаль районы бюджетына акчалар кергән көннән соң 3 (өч) эш көне эчендә күчерелә.

3.2. Субсидия алучы тарафыннан субсидияне чит ил валютасы акчалары исәбеннән алу тыела, моңа югары технологияле импорт җиһазларын, чималны һәм комплектлаучы әйберләрне сатып алганда (китергәндә) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләр, шулай ук әлеге акчаларны күрсәтелгән юридик затларга субсидияләр бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларда, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка максатларга ирешү белән бәйле операцияләр керми.

3.3. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү фактлары ачыкланган очракта, Башкарма комитет Субсидия алучыга тиешле субсидияләрне ачыкланган хокук бозуларны бетергәнче күчермәскә хокуклы.

3.4. Субсидияләр Субсидия алучының субсидияне бирү турындагы гаризасында күрсәтелгән Россия Федерациясендә урнашкан кредит оешмасындагы исәп-хисап счетына күчерелә.

## 4. Субсидияләрне кире кайтару тәртибе

4.1. Субсидия алучы тарафыннан субсидияне биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтелгән хокук бозулар ачыкланган көннән алып 10 көн эчендә Субсидия алучыга субсидияне кире кайтару турында таләп җибәрә.

4.2. Әлеге Килешүнең 4.1 пунктында күрсәтелгән хәлләр ачыкланганда, Субсидия алучы субсидияне мөстәкыйль рәвештә яисә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты таләбе буенча кире кайтаралар.

4.3. Акчаны кире кайтару Субсидия алучы игътибарына субсидияне кире кайтару турындагы таләпне җиткерелгәннән соң җиде эш көне дәвамында, әмма агымдагы елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

4.4. Субсидияләрне кире кайтару хәбәрнамәдә күрсәтелгән Россия Федерациясе бюджетлары керемнәре классификациясенең реквизитлары һәм коды буенча башкарыла.

4.5. Субсидия алучылар, тикшерелгән документлар нәтиҗәләре буенча билгеләнгән, шулай ук башка контроль чаралар үткәрү нәтиҗәсендә фактта барлыкка килгән керемнәрдән нигезсез рәвештә күрсәтелүче керемнәр күләмендә түләнгән керемнәр рәвешендә алынган бюджет акчаларын кире кайтарырга тиеш.

Ачыкланган хокук бозулар комиссия тарафыннан акт белән рәсмиләштерелә, имзалана һәм Субсидия алучыга бирелә.

4.6. Әлеге Килешүнең 4.5 п. күрсәтелгән актны алганнан соң 30 календарь көн эчендә Субсидия алучы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетының шәхси счетына агымдагы финанс елында артык алынган акчаларны кире кайтарырга тиеш.

4.7. Әлеге Килешүненең 4.3, 4.6. пунктларын үтәмәгән очракта, сумма недоимка булып санала һәм аңа вакыты узган һәр көн өчен 0,1% күләмендә пеня өстәлә.

4.8. Субсидияләр биргәндә билгеләнгән шартларны бозып файдаланылган субсидияләрне, шулай ук тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыкланган төшеп калган керемнәрнең нигезсез суммаларын бозып, кире кайтармаган яисә ирекле кире кайтармаган очракта, түләтү Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә башкарыла.

## 5. Субсидияләрнең калган өлешләрен кире кайтару тәртибе

5.1. Субсидия алучы агымдагы финанс елында субсидияләрнең калган өлешен кире кайтара, субсидия алучының акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә бирелгән субсидияләрдән тыш.

5.2. Субсидиянең калган өлешен кире кайтару Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитетына тиешле акчаларны күчерү юлы белән, субсидияне кире кайтару турындагы таләпне Субсидия алучыга җиткергән көннән алып җиде банк көне дәвамында, тик агымдагы финанс елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

5.3. Агымдагы елның декабрь аенда бирелгән субсидия тиешле субсидиядән артып киткән очракта, артык җибәрелгән сумма Арча муниципаль районы

бюджетына хисап елыннан соң килүче елның 25 гыйнварына кадәр кайтарылырга тиеш.

## 6. Йомгаклау нигезләмәләре

6.1. Әлеге Килешүнең гамәлдә булу срогы ____________________ ____________________.

6.2. Әлеге Килешү якларның үзара ризалыгы буенча үзгәртелергә яисә тулыландырылырга мөмкин. Әлеге килешүгә теләсә нинди үзгәрешләр һәм өстәмәләр аларны язма рәвештә беркеткән һәм ике як тарафыннан имзаланган очракта гына дөрес.

6.3. Әлеге Килешүгә кул куеп, Субсидия алучы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органы (Арча муниципаль районының контроль-хисап палатасы) тарафыннан субсидия бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүгә ризалыгын белдерә.

6.4. Әлеге Килешү ике нөсхәдә төзелде: берсе - Субсидия алучыга, икенчесе Башкарма комитетка бирү өчен. Барлык нөсхәләр дә тигез юридик көчкә ия.

## 7. Якларның адреслары һәм банк реквизитлары

| | |
|---|---|
| «Башкарма комитет» | "Субсидия алучы" |

8. Имзалар

| | |
|---|---|
| «Башкарма комитет» | "Субсидия алучы" |
| Мөһер урыны | Мөһер урыны |

"10" март ел, №153
килешүгә 1 нче кушымта

Форма

____________________ 20___елга

электрон бердәм социаль юл йөрү билетлары буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга бәйле компенсация түләүләре хисабы

| № | Шәһәрдә социаль юл йөрү билетлары һәм балалар өчен социаль юл йөрү билетлары буенча йөрүләр саны (факттагы транзакцияләр) | АСОП мәгълүматлары буенча шәһәр янында социаль юл йөрү билетлары һәм балалар өчен социаль юл йөрү билетлары буенча үтелгән пассажир-километр саны | Шәһәрдә пассажирлар ташуга ташламалы транспорт кушымталы электрон карта белән йөрү өчен билгеләнгән гамәлдәге тариф, сум | Шәһәр янында пассажирлар ташуның гамәлдәге тарифы, сум/км | Ташламалы транспорт карталары буенча транспорт хезмәтләре күрсәтү буенча транспорт оешмасы чыгымнары, сум | ЕМСПБ һәм ЕМДСПБ сату (тулыландыру) буенча транспорт оешмасы табышы, сум | Транспорт карталары буенча ташламалы транспорт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле рәвештә транспорт оешмаларына тиешле компенсация түләүләре күләме, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

Субсидия алучы җитәкчесе ______________________________________________
*(вәкаләтле зат)* *(имза)* *(имзаның аңлатмасы)*

Башкаручы ______________________________________________ "___ "_________________ ел
*(вазыйфасы)* *(ФИАИ)* *(телефон)*

10.03.2025 ел,
№153 килешүгә 2 нче
кушымта

Форма

_________________ елга транспорт оешмаларының җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүдә гражданнарга бердәм электрон социаль юл йөрү билетлары (ташламалы транспорт картасы) буенча хезмәт күрсәтүләр белән бәйле чыгымнары буенча хисап

| N | Транспорт оешмалары атамасы | Хисап аена үсә барган нәтиҗә белән тулыландырылганстәмә ташламалар саны тулыландырылган транспорт карталары/сатылган ЕМСПБ һәм ЕМДСПБ, данә | | | Хисап аена тулыландырылган ташламалы транспорт карталары/сатылган ЕМСПБ һәм ЕМДСПБ дан кергән табыш, үсә барган нәтиҗә, мең сум | | | Транспорт оешмасын компенса. күләме хисап аена аена үсә барган нәтиҗә, мең сум | Транспорт оешмасы чыгымнары хисап аена үсә барган нәтиҗә, мең сум | Фактта транспорт оешмаларына күчерелгән, (касса чыгымы) хисап аена үсә барган нәтиҗә, мең сум | Транспорт оешмасының хисап аена алынмаган компенсация күләме, үсә барган нәтиҗә, мең сум (гр.9 –гр. 11) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | тулыландырылган ташламалы транспорт карталары/ ЕМСПБ саны Хисап аена үсә баручы нәтиҗә, данә | тулыландырылганн балалар ташламалы транспорт карталары/ ЕМДСПБ саны хисап аена үсә барган нәтиҗә, данә | барлыгы данә (гр. 3 + гр. 4) | ташламалы транспорт карталары/ ЕМСПБ дан табышккерем табыш, мең сум | балалар ташламалы транспорт карталары/ ЕМДСПБдан табыш табыш, мең сум | барлыгы, сум (6 гр. + 7 гр.) | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |

Субсидия алучы житәкчесе ______________________________
(вәкаләтле зат) (имза) (имзаның аңлатмасы)

Башкаручы ______________________________ "___"_______________ ел
(вазыйфасы) (ФИАИ) (телефон)